ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БУГУЛЬМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БӨГЕЛМӘ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

12.09.2019 г. Бугульма № 543

**Бөгелмә муниципаль районы Башкарма комитетының**

**2018 елның 17 декабрендә кабул иткән**

**759нчы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Законга туры китерү максатында карар бирәм:

1. Бөгелмә муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 17 декабрендә кабул иткән "Элек хосусыйлаштырылган торак биналарны муниципаль милек итеп кабул итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында"гы 759нчы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2нче бүлектә:

- 2.6нчы пунктны түбәндәге аспункт белән тулыландырырга:

«5) СНИЛС.»

1.2. 3нче бүлектә:

- 3.4.1нче аспунктны:

«5) СНИЛС.» дигән сүзләр белән тулыландырырга.

1.3. 5нче бүлекне яңа басмада бәян итәргә:

**«5. Муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның җитәкче затының, яисә муниципаль хезмәткәрнең, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең, шулай ук муниципаль хезмәт күрсәтү функцияләрен башкаручы оешмаларның, яисә аларның хезмәткәрләренең карарларына, гамәлләрен (гамәл кылмауларын) шикаять белдереп гариза язучы тарафыннан судка кадәр (судтан башка) тикшерү**

5.1. Шикаять кәгазьдә, язма рәвештә, электрон формада муниципаль хезмәт күрсәтүче органга, күпфункцияле үзәккә яки күпфункцияле үзәкне оештыручы булып тора торган тиешле дәүләт хакимияте органына (алга таба –

күпфункцияле үзәкне оештыручы), һәм шулай ук 210нчы Федераль законның 16нчы маддәсенең 1.1нче өлешендә каралган оешмаларга бирелә. Муниципаль хезмәт күрсәтүче орган җитәкчесенең карарлары, гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата язылган шикаятьләр муниципаль хезмәт күрсәтүче органның җитәкчесе тарафыннан карала. Күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата язылган шикаятьләр әлеге күпфункцияле үзәкнең оештыручысына яки Россия Федерациясе субъектының хокукый-норматив акты белән вәкаләт бирелгән вазыйфаи затка тапшырыла. 210нчы Федераль законның 16нчы маддәсенең 1.1нче өлешендә каралган оешма хезмәткәренең карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата язылган шикаятьләр әлеге оешмаларның җитәкчеләренә тапшырыла.

Сораучы-өрәҗәгать итүче шул исәптән түбәндәге очракларда шикаять белән мөрәҗәгать итәргә хокуклы:

1) муниципаль хезмәт сораучы-мөрәҗәгать итүченең үтенечен теркәү срогы бозылса, 210нчы Федераль законның 15.1нче маддәсендә күрсәтелгән запросны теркәү срогы бозылса;

2) муниципаль хезмәт күрсәтү срогы бозылса. Әлеге очракта күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата язылган шикаятьне судка кадәр (судтан башка) тикшерү әлеге күпфункцияле үзәккә тиешле муниципаль хезмәтләрне 210нчы Федераль законның 16нчы маддәсенең 1.3нче өлешендә каралган тәртиптә һәм тулы күләмдә күрсәтү бурычы йөкләнгәнгәндә мөмкин була;

3) сораучы-мөрәҗәгать итүчедән муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен Россия Федерациясе, Россия Федерациясе субъектларының хокукый-норматив актларында, муниципаль хокукый-норматив актларда күрсәтелмәгән документларны яки мәгълүматларны сорау, яисә башка төрле гамәлләр башкаруны таләп итү;

4) сораучы-мөрәҗәгать итүчедән муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен Россия Федерациясе, Россия Федерациясе субъектларының хокукый-норматив актларында, муниципаль хокукый-норматив актларда күрсәтелгән документларны кабул итүдән баш тарту;

5) муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту, әгәр федераль законнарда һәм Россия Федерациясенең аларга туры китереп кабул ителгән хокукый-норматив актларында, Россия Федерациясе субъектлары законнарында яки аларга туры китереп кабул ителгән хокукый-норматив актларында, муниципаль хокукый актларында баш тарту өчен нигез күрсәтелмәгән булса. Бу очракта күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата язылган шикаятьне судка кадәр (судтан башка) тикшерү

әлеге күпфункцияле үзәккә тиешле муниципаль хезмәтләрне 210нчы Федераль законның 16нчы маддәсенең 1.3нче өлешендә каралган тәртиптә һәм тулы күләмдә күрсәтү бурычы йөкләнгәндә мөмкин була;

6) муниципаль хезмәт күрсәткәндә, сораучыдан Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Бөгелмә муниципаль районы хокукый-норматив актларында каралмаган түләүне таләп итү;

7) муниципаль хезмәт күрсәтүче органның муниципаль хезмәт күрсәтүче органның җитәкче затының, яисә муниципаль хезмәткәрнең, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең, шулай ук муниципаль хезмәт күрсәтү функцияләрен башкаручы оешмаларның, яисә аларның хезмәткәрләренең, 210нчы Федераль законның 16нчы маддәсенең 1.1нче өлешендә каралган оешма хезмәткәренең муниципаль хезмәт күрсәткәндә документта җибәргән ялгышларын яки хаталарын төзәтүдән баш тартуы, яисә аларны төзәтү срогын бозуы. Андый очракларда күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата язылган шикаятьне судка кадәр (судтан башка) тикшерү әлеге күпфункцияле үзәккә тиешле муниципаль хезмәтләрне 210нчы Федераль законның 16нчы маддәсенең 1.3нче өлешендә каралган тәртиптә һәм тулы күләмдә күрсәтү бурычы йөкләнгәндә мөмкин була;

8) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре буенча документлар бирү срогын, яисә тәртибен бозу;

9) муниципаль хезмәт күрсәтү эшен туктату, әгәр аны туктату өчен әгәр федераль законнарда һәм Россия Федерациясенең аларга туры китереп кабул ителгән хокукый-норматив актларында, Россия Федерациясе субъектлары законнарында яки аларга туры китереп кабул ителгән хокукый-норматив актларында, муниципаль хокукый актларында баш тарту өчен нигез күрсәтелмәсә. Мондый очракларда күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата язылган шикаятьне судка кадәр (судтан башка) тикшерү әлеге күпфункцияле үзәккә тиешле муниципаль хезмәтләрне 210нчы Федераль законның 16нчы маддәсенең 1.3нче өлешендә каралган тәртиптә һәм тулы күләмдә күрсәтү бурычы йөкләнгәндә мөмкин була;

10) муниципаль хезмәт турында сораучы-белдерүчедән беренче тапкыр документлар кабул иткән чакта мәгълүмат юклыгы һәм (яки) төгәл түгеллеге күрсәтелмәгән (әйтелмәгән) булса, документлар яки мәгълүматлар таләп итү, 210нчы Федераль законның 7нче маддәсенең 1нче өлешенең 4нче пунктында каралган очраклардан тыш. Мондый очракларда күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата язылган шикаятьне судка кадәр (судтан башка) тикшерү

әлеге күпфункцияле үзәккә тиешле муниципаль хезмәтләрне 210нчы Федераль законның 16нчы маддәсенең 1.3нче өлешендә каралган тәртиптә һәм тулы күләмдә күрсәтү бурычы йөкләнгәндә мөмкин була

5.2. Муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның җитәкче затының, яисә муниципаль хезмәткәрнең, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең, шулай ук муниципаль хезмәт күрсәтү функцияләрен башкаручы оешмаларның, яисә аларның хезмәткәрләренең карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять почта аша, күпфункцияле үзәк аша, “Интернет” телекоммуникацион мәгълүмат челтәрен, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның рәсми сайтын (http://www.bugulma.tatar.ru), Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталын (http://uslugi.tatar.ru), дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталын (http://www.gosuslugi.ru) файдаланып бирелергә мөмкин, шулай ук гариза шәхсән кабул итү вакытында тапшырыла ала. Күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять почта аша җибәрелә, “Интернет” телекоммуникацион мәгълүмат челтәрен, күпфункцияле үзәкнең рәсми сайтын, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталын, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең региональ порталын файдаланып бирелергә мөмкин, шулай ук гариза шәхсән кабул итү вакытында тапшырыла ала. 210нчы Федераль Законның 16нчы маддәсенең 1.1нче өлешендә каралган оешма хезмәткәренең карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата язылган шикаятьләр “Интернет” телекоммуникацион мәгълүмат челтәрен, ул оешмаларның рәсми сайтын, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталын, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең региональ порталын файдаланып бирелергә мөмкин, шулай ук гариза шәхсән кабул итү вакытында тапшырыла ала

5.3. Муниципаль хезмәт күрсәтүче органга, күпфункцияле үзәккә, муниципаль хезмәт күрсәтү функцияләрен башкаручы оешмаларга, 210нчы Федераль законның 16нчы маддәсенең 1.1нче өлешендә каралган оешмага, яисә югарырак органга (әгәр ул булса) кергән шикаять аны теркәгән көннән алып, унбиш эш көне эчендә тикшерелргә тиеш, ә муниципаль хезмәт күрсәтүче орган, күпфункцияле үзәк, муниципаль хезмәт күрсәтү функцияләрен башкаручы оешма, 210нчы Федераль законның 16нчы маддәсенең 1.1нче өлешендә каралган оешма муниципаль хезмәт күрсәткәндә җибәргән хата я ялгышны төзәтү өчен документларны кабат кабул иткәндә – аны теркәгәннән алып биш көн эчендә.

5.4. Шикаятьтә түбәндәге мәгълүматлар булырга тиеш:

1) карарлары, гамәлләре (гамәл кылмаулары) карата шикаять бирелә торган муниципаль хезмәт күрсәткән орган, муниципаль хезмәт күрсәткән

органның вазыйфаи заты, яисә муниципаль хезмәткәрнең, күпфункцияле үзәкнең, аның җитәкчесенең һәм (яки) муниципаль хезмәт күрсәтү функцияләрен башкаручы оешмаларның, яисә аларның хезмәткәрләренең, 210нчы Федераль законның 16нчы маддәсенең 1.1нче өлешендә каралган оешма хезмәткәренең исем һәм атамалары;

2) гариза язучы физик затның исеме, фамилиясе, отчествосы (булган очракта), яшәү урыны яки аның хәзерге вакытта тору урыны турында мәгълүмат, юридик затлар өчен – атамасы, урнашкан урыны турында мәгълүмат, шулай ук телефон номеры (номерлары), электрон почта адресы (әгәр булса), җавап җибәрү мөмкин булган почта адресы;

3) муниципаль хезмәт күрсәткән орган, муниципаль хезмәт күрсәткән органның вазыйфаи заты, яисә муниципаль хезмәткәрнең, күпфункцияле үзәкнең, аның җитәкчесенең һәм (яки) муниципаль хезмәт күрсәтү функцияләрен башкаручы оешмаларның, яисә аларның хезмәткәрләренең, 210нчы Федераль законның 16нчы маддәсенең 1.1нче өлешендә каралган оешма хезмәткәренең шикаять белдерелә торган гамәлләре (гамәл кылмаулары) турында мәгълүматлар;

4) муниципаль хезмәт күрсәткән орган, муниципаль хезмәт күрсәткән органның вазыйфаи заты, яисә муниципаль хезмәткәрнең, күпфункцияле үзәкнең, аның җитәкчесенең һәм (яки) муниципаль хезмәт күрсәтү функцияләрен башкаручы оешмаларның, яисә аларның хезмәткәрләренең, 210нчы Федераль законның 16нчы маддәсенең 1.1нче өлешендә каралган оешма гамәлләреннән (гамәл кылмауларыннан) ни сәбәпле риза булмауны нигезләү. Шикаять язучы үзенең нигезләүләрен раслый торган документларны, яисә аның күчермәләрен бирә ала.

5.5. Шикаятькә анда бәян ителгән шартларны раслый торган документларның күчермәләре кушып бирелә ала. Бу очракта шикаять белән бергә бирелә торган ул документларның исемлеге дә китерелә.

5.6. Шикаятькә аны язучы муниципаль хезмәт алган кеше имза куя. 5.7. Шикаятьләрне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән, кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, муниципаль хезмәт күрсәтү вакытында документларда киткән хата я ялгышларны төзәтү, сораучыга Россия Федерациясе, Россия Федерациясе субъектларының хокукый-норматив актлары, муниципаль хокукый-норматив актларда каралмаган түләү алган акчаны кайтарып бирү формасында;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла. Әлеге пунктта күрсәтелгән карарны кабул иткәннең икенче көненнән дә соңга калмыйча, гариза язучыга

язма формада һәм, аның теләге буенча, электрон формада шикаятьне карау нәтиҗәләре турында мотивацияле җавап җибәрелә.

5.8. Шикаятьне канәгатьләндерергә кирәк дип табылган очракта, сораучыга бирелгән җавапта Башкарма комитет, күпфункцияле үзәк яки 210нчы Федераль законның 16нчы маддәсенең 1.1нче өлешендә каралган оешма тарафыннан, муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә ачыкланган ялгышларны кичекмәстән бетерү өчен башкарыла торган эшләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китергән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм муниципаль хезмәт алсын өчен сораучыга арытаба ниләр эшләргә кирәклеге турында мәгълүмат бирелә.

5.9. Шикаятьне канәгатьләндерергә кирәк түгел дип табылган очракта, сораучыга җавапта кабул ителгән карарның сәбәпләре турында нигезле аңлатма бирелә, һәм шулай ук әлеге карар белән килешмәгән очракта аның өстеннән шикаять бирү тәртибе аңлатыла.

5.10. Шикаятьне карау барышында яки аны тикшерү нәтиҗәләрендә административ хокук бозу яки җинаять билгеләре күренә икән, шикаятьне карарга хокук бирелгән вазыйфаи зат, хезмәткәр булган материалларны кичекмәстән прокуратурага җибәрәләр.

2. Текстның калган өлешен үзгәрешсез калдырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешенә контрольлек итүне ТР Бөгелмә муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең икътисадый үсеш мәсьәләләре буенча урынбасарына йөклим.

**Җитәкче вазыйфаларын башкаручы** **В.В. Гарәфетдинов**